| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
|---|---|
| 7 июнь 2022 ел | № 134 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына туры китереп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәгә Балтач район прокуратурасының 2022 елның 6 маендагы 02-08-01-2022 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. 2014 елның 27 мартындагы 216 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- Нигезләмәнең 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. Палатаны палата эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүче рәис җитәкли. Палата рәисе вазыйфага Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар арасыннан, Район Башлыгы белән килештереп, Район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Палата рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин